# КАРАР

« 07 » апрель 2024 ел № 9

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Иске Кенәр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Иске Кенәр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 , 56 статьяларына, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Кенәр авылында 2024 елның 06 апрелендә «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Иске Кенәр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 нояберендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе тәзелде:

Сез 2024 елда Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Г.Тукай урамы);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар

электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары ясау, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү ?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 82 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 51 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 49 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль район Ташкичү авыл җирлеге Иске Кенәр авылында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Сез 2024 елда Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Г.Тукай урамы);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар

электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары ясау, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга» соравы буенча карар кабул ителде дип танырга».

3. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урыннарда: ТР, Арча районы, Иске Кенәр авылы, Тукай, 9 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Ташкичү авылы җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин